| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**БОЕРЫГЫ** |
| 21.12.2024 | | № 406 |

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертү турында**

Пилотсыз очу аппаратлары белән массакүләм һөҗүм нәтиҗәсендә 2024 елның 21 декабрендә Казан шәһәрендә килеп туган гадәттән тыш хәлнең нәтиҗәләрен бетерү максатында, «Халыкны һәм территорияләрне табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен, махсус боерык чыкканга кадәр, 2024 елның 21 декабреннән гадәттән тыш хәл режимы кертергә һәм төбәк дәрәҗәсендә чаралар күрелергә тиешлеген билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гадәттән тыш хәл режимында эшләгәндә Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре эшчәнлеген координацияләүне;

әлеге боерыкны үтәгәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның гамәлләрен килештерүне.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ